ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2021 ел Ульянково ав. № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлегенең Корноухово авылында гражданнар жыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Корноухово авылы, Бутанина урамы, 44 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Корноухово торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар жыеның беренче этабын билгеләргә.
2. 2021 елның 25 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Корноухово авылы, Бутанина урамы, 58 нче йорт адресы буенча урнашкан Корноухово авыл клубында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлеге Корноухово торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар жыеның икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл жирлегенең Корноухово авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәргәндә Ульянково авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) авыруы очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларны үтәүне тәэмин итәргә.
6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Ульянково авыл җирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**